СОВЕТ
НАЛАСИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Вахитова, д. 64, с.Наласа,
Арский муниципальный район, 422018

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
НАЛАСА
АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
М.Вахитов урамы, 64 йорт, Наласа авылы,
Арча муниципаль районы, 422018

Тел. (84366)50-2-25, факс (84366)50-2-25. E-mail: Nalas.Ars@tatar.ru

**Наласа авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**03 декабрь 2018 ел** **№73**

**Җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон һәм Наласа авыл җирлеге Уставы нигезендә Наласа авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районына муниципаль берәмлекнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләре буенча вәкаләтләрнең бер өлешен

1) муниципаль берәмлектә муниципаль хезмәткәрләр реестрын алып бару буенча;

2) муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфаларын биләүгә конкурс үткәрү;

3) вакантлы идарәчелек вазыйфаларын һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен кадрлар резервын формалаштыру буенча үзара хезмәттәшлекне оештыру;

4) муниципаль хезмәткәрләргә аттестация үткәрү;

5) муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның һәм Арча муниципаль районы муниципаль берәмлекләренең муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи хәле яисә аларның хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәве, бүләкне тапшыру һәм бәяләү, бүләкне реализацияләү (сатып алу) һәм гамәлгә ашырудан килгән акчаларны алу турында хәбәр итү тәртибенә бәйле эшчәнлек алып бару;

6) муниципаль берәмлектә хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Комиссия төзү һәм аның эшчәнлеге;

7) Арча муниципаль районы җирле үзидарә органнарының квалификация имтиханын кабул итү, сыйныф чиннарын бирү буенча;

8) җирле үзидарә органында муниципаль вазыйфаларны һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм

мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр урнаштыру; Арча муниципаль районының рәсми сайтында;

9) Арча муниципаль районының муниципаль вазыйфаларны һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затларга диспансеризация оештыру буенча;

10) Арча муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль вазыйфаларны һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затларны биләүче өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру буенча;

11) «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтнең кадрлар составының бердәм мәгълүмат системасы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасына белешмәләр кертү, урнаштырылган белешмәләрне актуальләштерү буенча.

12) җирлек бюджетының үтәлешен тикшереп тору буенча.

13) җирлек бюджеты проектларына экспертиза буенча.

14) җирлек бюджетының үтәлеше турындагы еллык хисапны тышкы тикшерү буенча.

15) җирлек бюджеты акчаларыннан файдалануның законлылыгын, нәтиҗәлелеген (нәтиҗәлелеген һәм экономиялелеген), шулай ук җирле бюджет тарафыннан Россия Федерациясе законнарында каралган башка чыганаклардан алына торган акчаларны тикшереп торуны оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча.

16) җирле бюджет акчалары исәбеннән салым һәм башка ташламалар һәм өстенлекләр, бюджет кредитлары бирүнең нәтиҗәлелеген бәяләү, шулай ук муниципаль гарантияләр бирүнең һәм йөкләмәләрне юридик затлар һәм индивидуаль эшкуарлар тарафыннан җирле бюджет акчалары һәм җирлек милкендәге мөлкәт исәбеннән башкарылган алыш-бирешләр буенча яисә үтәүне тәэмин итүнең законлылыгын бәяләү буенча.

17) муниципаль хокукый актлар проектларына (финанс-икътисадый нигезләүләрнең нигезлелеген дә кертеп) җирлекнең чыгым йөкләмәләренә, шулай ук муниципаль программаларга кагылышлы өлешендә финанс-икътисадый экспертиза ясау буенча.

18) җирлектә бюджет процессын анализлау һәм аны камилләштерүгә юнәлтелгән тәкъдимнәр әзерләү.

19) җирлекнең җирле бюджетын үтәүнең барышы, үткәрелгән контроль һәм эксперт-аналитик чараларның нәтиҗәләре турында мәгълүмат әзерләү һәм мондый мәгълүматны Арча муниципаль районы Советына һәм муниципаль район башлыгына тапшыру.

20) коррупциягә каршы юнәлдерелгән чараларда вәкаләтләр чикләрендә катнашу буенча.

21) федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында, җирлекнең уставында һәм норматив хокукый актларында билгеләнгән тышкы муниципаль финанс контроле өлкәсендәге башка вәкаләтләр.

22) эчке финанс контролен гамәлгә ашыру буенча:

- бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган Россия Федерациясе бюджет законнарын һәм башка норматив хокукый актларны үтәүне;

- муниципаль программаларны гамәлгә ашыру турында, шул исәптән муниципаль биремнәрне үтәү турында хисаплылыкның тулылыгы һәм дөреслеге өчен.

23) җирлек җирле үзидарә органнарының норматив-хокукый актларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру буенча.

24) жирлекнең җирле үзидарә органнары исеменнән электрон аукцион йомгаклары буенча төзелә торган контракт проектының квалификацияләнмәгән көчәйтелгән электрон имзасы белән имза кую;

25) «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяжларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 05 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законда каралган мәгълүмат һәм документларның бердәм мәгълүмат системасында урнаштыру буенча.

26) муниципаль милек реестрын һәм җирлекләрнең муниципаль җирләре реестрын алып бару, муниципаль мөлкәтне, жир ресурсларын исәпкә алу системасы эшләвен тәэмин итү, жирлекнең муниципаль мөлкәте барлыгы һәм алардан файдалану турындагы мәгълүматның тулылыгы һәм дөреслеге;

27) җирлекнең муниципаль милкендәге мөлкәт мәсьәләсе, аны биләү, алардан файдалану һәм аның белән эш итү.

2. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы» муниципаль берәмлеге белән «Арча муниципаль районының Наласа авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирле әһәмияттәге мәсьәләләре буенча вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында килешүне 1.3 пункты нигезендә төзергә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http:pravo.tatarstan.ru)

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Наласа авыл җирлеге башлыгы И.Р.Шакирова